Камышлинские известия

газета основана в 1931 году

ГАЗЕТА МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА КАМЫШЛИНСКИЙ

12+

8 февраля 2019 года Пятница №9 (9687)

ХОРОШАЯ НОВОСТЬ

Благодаря губернаторскому проекту “СОдействие” в Камышлинском районе появятся новые объекты

Губернаторский проект «СОдействие» в рамках областной программы «Поддержка инициатив населения» действует на территории губернии с 2017 года.

Четыре социальных проекта на территории Камышлинского района стали его победителями и будут реализованы в этом году. Успешно прошли конкурсный отбор такие общественные проекты, как строительство детской площадки «Дворик детства» и детской игровой площадки «Муравейник» в сельском поселении Байтуган, реконструкция памятника Великой Отечественной войны в селе Старая Балыкла, создание парка отдыха в селе Старое Усманово.

ПФР СООБЩАЕТ

Прожиточный минимум камышлинского пенсионера не изменился

В 2019 году в Самарской области величина прожиточного минимума пенсионера в целях установления социальной доплаты к пенсии составил 8413 руб. (то есть столько же, сколько и в 2018 году).

Отдел пенсионного фонда России Камышлинского района напоминает, что неработающим пенсионерам, общая сумма материального обеспечения которых меньше указанной величины, предоставляется социальная доплата к пенсии до уровня прожиточного минимума пенсионера. Таким образом, в 2019 году в Самарской области социальная доплата устанавливается до уровня 8413 руб.

При подсчете общей суммы материального обеспечения пенсионера учитываются все виды пенсий, ежемесячная денежная выплата (включая стоимость набора социальных услуг), дополнительное материальное (социальное) обеспечение и иные меры социальной поддержки (помощи), установленные законодательством субъектов Российской Федерации в денежном выражении (за исключением мер социальной поддержки, предоставляемых единовременно).

Важно! Получатели социальной доплаты к пенсии могут не увидеть увеличения пенсии с 1 января 2019 года. При увеличении пенсии размер доплаты уменьшается, так что уровень дохода остается прежним – 8 413 рублей.

Детям-инвалидам и детям, которым установлена пенсия по случаю потери кормильца, не достигшим возраста 18 лет, социальная доплата производится в беззаявительном порядке. Неработающим гражданам, обратившимся с заявлением о назначении пенсии в 2018 году и выразившим в нем свое согласие на установлении федеральной социальной доплаты к пенсии, доплата, при наличии права, будет установлена без истребования дополнительных документов.

Обращаем внимание! Все получатели социальной доплаты к пенсии в случае устройства на работу и (или) осуществления иной деятельности, в период которой они подлежат обязательному пенсионному страхованию, обязаны известить об этом территориальный орган Пенсионного фонда РФ по месту получения пенсии. В случае неисполнения указанного обязательства и выплаты в связи с этим излишних сумм социальной доплаты к пенсии, гражданин обязан возместить в федеральный бюджет причинённый ущерб.

Как проиндексируют пенсии с 1 января 2019 года

С 1 января 2019 года страховые пенсии неработающих пенсионеров проиндексируют на 7,05%, что выше показателя прогнозной инфляции по итогам 2018 года. Таким образом, размер фиксированной выплаты после индексации составит 5334,2 рубля в месяц, а стоимость страхового балла — 87,24 рубля. При этом у каждого пенсионера прибавка к пенсии будет индивидуальной в зависимости от размера пенсии. Чем выше приобретённые у гражданина в течение трудовой жизни пенсионные права (стаж, заработок, страховые взносы, количество пенсионных коэффициентов), тем больше размер страховой пенсии и, следовательно, сумма прибавки к ней после индексации.

В соответствии с пенсионным законодательством выплата начисленных сумм пенсии производится на текущий месяц. Пенсионер самостоятельно выбирает способ доставки пенсии: через Почту России или через один из банков, заключивших соглашение с Пенсионным фондом.

В АДМИНИСТРАЦИИ РАЙОНА

ИМИДЖ РАЙОНА КАК РЕСУРС ЕГО УСПЕШНОГО РАЗВИТИЯ

Ирина Макарова.

В ЦЕНТРЕ ВНИМАНИЯ - РЕМОНТ ДОРОГ…

В Камышлинском районе продолжается подготовка к X Всероссийскому сельскому Сабантую, который впервые примет район летом 2019 года.

В рамках подготовки к мероприятию 5 февраля в кабинете главы района Р.К. Багаутдинова состоялось выездное совещание под председательством заместителя министра – руководителя департамента автомобильных дорог Самарской области А.Ю.Спиридонова. Обсуждались вопросы проведения ремонта дорог и тротуаров в селе Камышла.

На сегодняшний день уже состоялись торги по определению подрядчика, и заключен муниципальный контракт с ООО «ВолгаСтройАльянс».

Напомним, в рамках подготовки к Сабантую предстоит ремонт тротуара и проезжей части по ул.Победы, ремонт дороги и строительство тротуара по ул.-Советской и Комсомольской, завершение строительства тротуара по ул. Красноармейской, а также ремонт проезжей части по ул. Коммуны.

Кроме того, в 2019 году в рамках регионального ремонта дорог, планируется ремонт дороги от ДРП-3 до моста через реку Сок автодороги Похвистнево-Клявлино.

«В графике работ необходимо отразить сроки подготовительных работ, сроки по ремонту проезжей части, по строительству тротуаров и закрепить по датам. Это даст возможность контролировать подрядчика», - подчеркнул заместитель министра.

…УЧАСТИЕ ОБЩЕСТВЕННОСТИ

В этот же день в формате живого диалога состоялось заседание районного общественного совета при участии главы района Рафаэля Багаутдинова.

В ходе заседания был затронут ряд актуальных для общественной жизни района вопросов. Рафаэль Камилович рассказал об итогах прошлого года, проинформировал о ходе подготовки к Всероссийскому сельскому Сабантую. «Общественный совет - это связующее звено между властью и жителями района», - подчеркнул в своем выступлении Р.К.Багаутдинов.

С информацией о реализуемых федеральных и региональных программах и проектах в муниципалитете выступил заместитель главы района по строительству и ЖКХ Руслан Абраров.

В немалой степени глава района ждёт от членов совета конкретных предложений и активной помощи и участия общественности в решении возникающих вопросов и проблем, имеющих большое значение для жизнедеятельности и имиджа муниципального района.

ЭКОНОМИКА

В сельском поселении Камышла ведется замена осветительных ламп

Ирина Макарова.

В последнее время вопросы экономии энергии стоят очень остро. Если граждане могут ограничить себя в использовании электроэнергии, то власти поселения не вправе отказаться от уличного освещения. Решить проблему можно лишь модернизацией систем электроснабжения и всей осветительной инфраструктуры.

В настоящее время электриком поселения Камышла Рафисом Гиззатовым при помощи работников поселения и МКУ «Благоустройство» ведётся работа по переводу уличного освещения на диодные лампы.

Уже произведена замена 570 ламп на новые экономичные. Полностью заменены светильники в селе Камышла и поселке Южный. В дальнейшем данная работа будет продолжена и в других селах поселения.

Такой ход даст значительную экономию бюджетных средств.

ЮБИЛЕЙ

ПЕСНЯ ДЛИНОЮ В ЖИЗНЬ

Ирина Макарова.

Сколько песен спето Дильбар Шигаповой подсчитать невозможно, поскольку выступлений на сцене в ее жизни было очень много.

В конце января в центре социального обслуживания населения состоялось мероприятие, посвященное 80-летию Дильбар Шигаповой. Множество поздравлений в этот день прозвучало в ее адрес.

Родилась Дильбар Мухтабаровна в 1939 году. Когда началась Великая Отечественная война, ей было всего 2,5 года. Отец - Мухтабар Сабирович отклонил шестимесячную бронь и отправился на фронт. Мама Шарифа осталась с двумя детьми на руках. Днем она работала в педучилище, а вечера проводила в клубе, где вела драматический кружок. Мухтабар Сабирович дошел до Берлина, встретил победу, но демобилизован был лишь летом 1946 года.

В школе голосистая девочка быстро стала школьной активисткой и певицей. В составе группы лучших учеников побывала в Москве.

За плечами Дильбар – огромный опыт работы на разных должностях. В свое время она вела увлекательный драматический кружок в Доме пионеров с.Камышла, в 1953г. стала заведующей орготделом Камышлинского райкома ВЛКСМ, впоследствии была назначена секретарем комсомольской организации.

Дильбар Мухтабаровна всегда ответственно выполняла свои обязанности и при этом имела массу общественных нагрузок, которые также отнимали немало сил.

После свадьбы Дильбар вместе с супругом отправляются на работу в Среднюю Азию.

Спустя пару лет семья Шигаповых вернулась на волжскую землю в г.Отрадный.

В 1996 году наша героиня вернулась в родную Камышлу. Здесь она устроилась на работу в местное отделение страховой компании и трудилась до 65 лет.

Много у этой энергичной женщины грамот, дипломов и благодарственных писем за эффективную активность в разных направлениях.

В настоящее время Дильбар Мухтабаровна является членом вокального ансамбля «Сударушка», который функционирует при Комплексном Центре социального обслуживания населения, волонтером «Серебряного возраста», принимает активное участие во многих мероприятиях, проводимых в Центре, в районе и области.

С праздником юбиляршу поздравила руководитель комитета культуры, спорта и молодежной политики Р.М.Тухбатшина и зачитала поздравительный адрес от имени главы района Р.К.Багаутдинова.

За выдающиеся заслуги, талант и стремление Шигапова Дильбар Мухтабаровна награждена медалью «Выдающаяся личность» от комитета, культуры, спорта, туризма и молодежной политики администрации муниципального района Камышлинский.

Теплые слова поздравлений, стихи, песни прозвучали также от центра культуры и досуга с.Камышла, руководства центра социального обслуживания, ветеранских организаций, главы поселения, друзей и благополучателей центра.

Именинница поделилась воспоминаниями своей жизни, поблагодарила всех за оказанное ей внимание.

ПОКОЛЕНИЕ ПАТРИОТОВ

ЮНАРМИЯ: НОВОЕ МОЛОДЕЖНОЕ ДВИЖЕНИЕ

В КАМЫШЛИНСКОМ РАЙОНЕ ПИЛОТНОЙ ПЛОЩАДКОЙ СТАЛА ШКОЛА СЕЛА КАМЫШЛА

Илюся Гайнуллина.

Надо отметить, в районе создана разветвленная сеть различных военно-спортивных и патриотических инициатив. Активно возрождаются лучшие советские традиции. К примеру, военно-спортивная игра «Зарница» сегодня превратилась в масштабное мероприятие. В образовательных организациях действуют военно-патриотические клубы. На базе Камышлинской школы открыт кадетский класс.

Еще одно масштабное военно-патриотическое движение - «Юнармия» - на территории района, по сути, находится на стадии становления и признана объединить разрозненные движения патриотической направленности. В этом году такой школьный юноармейский отряд, который объединит ребят, создается на базе Камышлинской школы. Сейчас активно решаются организационный и финансовый вопросы. В результате из числа участников военно-патриотического клуба, «Зарницы», кадетского класса будет сформирован один юнармейский отряд. Определился педагог, который с ними будет заниматься и курировать - учитель ОБЖ и физической культуры С.П. Мискин.

А.Х. Каюмова, директор Камышлинской школы:

- Юнармейское движение в нашей школе только начинает развиваться: 37 школьников, которые, так или иначе, имеют первичный опыт патриотического движения, присоединятся к новому движению. Для них закуплен комплект юнармейской формы, спонсорскую поддержку в этом оказала администрация сельского поселения Камышла. На повестке - внесение юнармейцев в единый реестр участников Всероссийского детско-юношеского военно-патриотического общественного движения. Вступление в «Юнармию» потребует еще больше активных действий, упорства и трудолюбия у ребят. Задача же взрослых - направить их энергию в правильное русло, помочь им вырасти физически крепкими и здоровыми, воспитать подрастающее поколение на исторических примерах. Планов и надежд в связи с новым военно-патриотическим движением у нас много, ведь оно открывает множество дорог в будущее подрастающему поколению и даже поможет получить образовательные преференции: деятельность в «Юнармии» будет засчитываться ребятам при поступлении в вузы.

Военизированные подразделения детей массово создаются по всей стране. Новый проект Минобороны «Юнармия» – общественное движение, созданное по инициативе Министра обороны РФ С.К. Шойгу, одобренное Президентом РФ В.В. Путиным. Членом юнармии может стать любой школьник 8–18 лет. Основная задача движения - начальная военная допризывная подготовка, включающая в себя как физическое, так и интеллектуальное развитие молодежи, формирование правильных жизненных взглядов.

ИЗ ПОЧТЫ РЕДАКЦИИ

Детям о войне

75 лет назад, 27 января 1944 года была прорвана блокада Ленинграда, которая продолжалась 900 долгих дней и ночей. Юбилею прорыва блокады Ленинграда в Новоусмановской школе посвятили ряд мероприятий.

В классах провели час истории «900 легендарных дней». В ходе урока учащиеся ознакомились с одной из героических страниц истории нашей страны – событиями блокадного Ленинграда, с жизнью детей и взрослых людей в дни блокады. Ребята воссоздали некоторые трагические страницы из жизни детей блокадного Ленинграда; посмотрели кадры кинохроники основных событий блокады 1941–1944 гг. «Правда о блокаде Ленинграда»; мультфильм «Воспоминание». Ребята узнали, что символами жизни блокадного Ленинграда были хлеб и метроном. Мерный звук метронома звучал ежедневно, как сердце блокадного Ленинграда. Этот звук придавал жизненные силы изможденным осадой ленинградцам.

Учителя рассказали об односельчанах, которые приняли участие в прорыве блокады Ленинграда. Это о Сулеймане Давлейтшиевиче Загфарове и Закарии Надыршевиче Файрукшине. После этого сообщения дети прочувствовали подвиг наших ветеранов в годы ВОВ.

Ю.С. Курбангалиеева и Г.Н. Ахметова, классные руководители 1 и 2 классов.

В связи с переходом на прямые договора с потребителями
ООО " Газпром межрегионгаз Самара" осуществляет
НАБОР СОТРУДНИКОВ
в абонентские отделы и территориальные участки в следующих населенных пунктах Самарской области:

в городах - Самара, Сызрань, Похвистнево, Отрадный, Кинель, Октябрьск, Тольятти, Чапаевск, Новокуйбышевск.

в поселках - Нефтегорск, Суходол, Комсомольский (Кинельского района), Безенчук

в селах - Исаклы, Челно-Вершины, Шентала, Клявлино, Камышла, Сергиевск, Кошки, Елховка, Кинель-Черкассы, Кротовка (Кинель-Черкасского района),Утевка (Нефтегорского района), Богатое, Борское, Шигоны, Зольное (Жигулевского района), Большая Черниговка, Алексеевка, Большая Глушица, Приволжье, Пестравка, Красноармейское, Хворостянка.

В настоящее время **ТРЕБУЮТСЯ СОТРУДНИКИ**
следующих специальностей:

-начальник участка *-контролер*
-инженер по учету газа *-инженер-программист*
-техник-метролог *-метролог*
-инженер

Резюме можно высылать на электронные адреса:F0631201@samgas.ru и F0631202@samgas.ru

В теме письма обязательно укажите населенный пункт и название должности.

Справки по телефонам: 8(846)310-33-21;8(846)310-32-06

Извещение о необходимости согласования проекта межевания земельных участков, образованных путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:275

Кадастровым инженером Кондратьевым Дмитрием Александровичем, 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, д. 55, e-mail: knpz_04@mail.ru, телефон: (846-53) 2-20-51, квалификационный аттестат кадастрового инженера № 63-10-66, выполнен проект межевания земельных участков: 1-площадью 28,5 га (285000 кв.м.) в счет 3/42 доли; 2-площадью 9,5 га (95000 кв.м.) в счет 1/42 доли, образуемых путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:275, расположенного по адресу: Самарская область, Камышлинский район, в границах бывшего колхоза «Дружба». Заказчиком работ является Данилова Нина Спиридоновна (Самарская область, Камышлинский район, с. Никиткино, ул. Центральная, д. 1, тел. 89613878324).

С момента опубликования настоящего извещения до 16.00 11 марта 2019г. собственники земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:275 могут ознакомиться с проектом межевания по адресу: 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, 55, кадастровый инженер Кондратьев Д.А.

Возражения относительно размера и местоположения границ выделяемых в счет земельных долей земельных участков направлять по адресу: 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, 55, кадастровый инженер Кондратьев Д.А., до 16.00 11 марта 2019 г.

Извещение о необходимости согласования проекта межевания земельных участков, образованных путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:51

Кадастровым инженером Кондратьевым Дмитрием Александровичем, 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, д. 55, e-mail: knpz_04@mail.ru, телефон: (846-53) 2-20-51, квалификационный аттестат кадастрового инженера № 63-10-66, выполнен проект межевания земельного участка, площадью 38,0 га (380000 кв.м.) в счет 4/100 долей, образуемого путем выдела из земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:51, расположенного по адресу: Самарская область, Камышлинский район, в границах бывшего колхоза «Дружба». Заказчиком работ является Данилов Николай Яковлевич (Самарская область, Камышлинский район, с. Никиткино, ул. Центральная, д. 1, тел. 89613878324).

С момента опубликования настоящего извещения до 16.00 11 марта 2019г. собственники земельного участка с кадастровым номером 63:20:0000000:51 могут ознакомиться с проектом межевания по адресу: 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, 55, кадастровый инженер Кондратьев Д.А.

Возражения относительно размера и местоположения границ выделяемого в счет земельных долей земельного участка направлять по адресу: 446960, Самарская область, ст. Клявлино, ул. Советская, 55, кадастровый инженер Кондратьев Д.А., до 16.00 11 марта 2019 г.

КРОВЛЯ 3 дня
региональная сеть
ПРОФЛИСТ
М/ЧЕРЕПИЦА
САЙДИНГ
8 937 074-36-36
Выезд замерщика БЕСПЛАТНО!

ПРОДАЕТСЯ:
- бычки от одного до двух месяцев.
Тел: 8-927-831-16-26.

КУПЛЮ лосиные рога 500р./кг, пух гусиный 300р./кг.
Тел: 8-927-780-70-79.

Мир Комфорта www.mk163.ru 8-927-658-03-88 | 8-917-118-72-65
АНТЕННЫ
СПУТНИКОВОЕ ТВ от 2500 р. ЦИФРОВОЕ ТВ от 1700 р.
монтаж | настройка | обмен | ремонт | рассрочка

2019 ЕЛ - ТЕАТР ЕЛЫ

Бу кызыклы

Хөрмәтле укучыларыбыз! 2019 ел-театр елы. Бүгеннән без сезгә "Югары уңыш өчен", "Камышлы хәбәрләре" газеталарында төрле елларда чыккан мәкаләләр тәкъдим итә башлыйбыз. Минемчә бик тә кызыклы язмалар булыр ул.

Авыл клубында спектакль

25 январьда Иске Ярмәк авылының берничә йөз сайлаучысы авыл клубына җыелды. Бу көнне авыл яшьләре алар алдында Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану" дигән пьесасы белән чыктылар. Сайлаучылар спектакльдә катнашучы Гата Нәгыймуллин, Хәдичә Сафина, Тәлгать Рәхмәтуллин иптәшләрнең үз рольләрен башкаруларын яратып карадылар.

"Югары уңыш өчен", 1953 ел.

Спектакль уңышлы үтте

Күптән түгел Иске Усман авылы мәдәният йортында үзебезнең авылның үзешчән сәнгатьтә катнашучылары язучы Юныс Әминевның "Өти балак" исемле спектаклен куйдылар. Ул уңышлы үтте.

Үзешчән артистларыбызның барысы да гаиләле кешеләр. Шуңа да карамастан, эштән соң вакытларын кызганмыйлар, репетицияләргә йөриләр, ә спектакльләр хәзерләп сәхнәдә куюларын авыл халкы бик шатланып каршы алды.

Үзешчән сәнгать сөючеләребездән мәдәният йорты мөдире Рафаэль Нуретдинов, авылыбыз кибетенең сатучысы Гөлфия Нуретдинова, колхозда ягучы булып эшләүче Шәһит Сафин, сыер савучылар Фәнүзә Сафина һәм Фәния Шәймәрданова, шофер Минсәхи Шәймәрданов, колхоз идарәсе бухгалтеры Мәдинә Шәмсуллина, тракторчы Фаиль Хисаметдиновлар үзләренең рольләрен бик оста һәм аңлаешлы итеп башкардылар.

Тик шунысы борчый, безнең мәдәният йортында спектакльләр һәм концертлар бик сирәк була. Шуңа күрәдер инде, тамашачылар, артистларыбызны матур спектакль белән тәбрикләгәч, аларга чын күңелдән сәламәтлек, эшләрендә уңышлыклар, тигез һәм тыныч тормыш теләгәч, аларның мәдәният йортында ешрак чыгыш ясауларын үтенделәр.

М.Гыльфанова. "Камышлы хәбәрләре", Март, 1993 ел.

Безнең клубта

Иске Усман авылы клубында авыл халкына культуралы ял оештыруга зур әһәмият бирелә.

Клуб каршында драма түгәрәге эшли. Түгәрәк членнары аена 2-3 мәртәбә спектакль яки концерт бүлекләре белән сәхнәгә чыгалар. Күптән түгел алар Г.Камалның "Көндәш" пьесасын сәхнәдә куйдылар. Тамашачылар үзләренең драмтүгәрәге коллективының чыгышларын бик яратып карыйлар.

Н.Мирза, "Югары уңыш өчен", 1952 ел, апрель.

Тамашачылар канәгать калдылар

14 апрельдә район культура йорты каршындагы татар драма түгәрәге М.Фәйзинең "Асылъяр" дигән 5 пәрдәлек пьесасын сәхнәгә куйды.

Ярлы авыл егете ролен Ләбиб Шәрәфиев башкарды. Бу аның беренче җаваплы роле иде. Ләкин тамашачылар Шәрәфиевнең уеныннан бик канәгать калдылар.

С.Галимуллин. "Югары уңыш өчен", 1952 ел, апрель.

Культура йортында

23 октябрьда район культура йортында татар драмтүгәрәге көче белән драматург Г.Насрыйның "Кушнарат" дигән пьесасы сәхнәгә куелды.

Спектакль үзенә күп санда тамашачыларны җәлеп итте.

"Югары уңыш өчен", октябрь, 1952 ел.

Камышлылар бездә

Газетаның 21 октябрь санындагы "Халык театры үзенең исемен яклады" дигән баш астындагы мәкаләне укыгач, кулыма каләм алырга мәҗбүр булдым.

Хөрмәтле Камышлы халык театрының үзешчән артистлары! Мин сезне бу исемне яклавыгыз һәм аклавыгыз белән чын күңелдән котлыйм. Сезнең бу күркәм хезмәтегездә иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек, тормыш юлларыгызда юлдашыгыз гел бәхет булуын телим.

Ә хәзер "Күрше кызы" спектакленең Яңа Усман авылы культура йортында куелуы турында язып үтми булмый. Әйе, спектакль тамашачыларга бик ошады. Барлык катнашучылар да дөрес сайланганнар. Пьесаның эчтәлеген дөрес ачуда үзләрен профессиональ актерлардан ким күрсәтмәделәр. Алар барысы да мактауга лаеклы, ләкин барысы турында аерым-аерым язып тору кирәк булмас дип уйлыйм. Тамашачылар аларның барысын да алкышлап озатып калдылар.

Мөхтәбәр Төхбәтшинның сәхнә осталыгының башы 1944-1945 елларда ук башланган иде бугай. Мин педучилищеда укыганда, мин тора торган квартирада яшьләр җыелып, пьесалар уйнап кич утыра торган идек. Төхбәтшин шунда ук бик оста итеп уйный торган иде. Ул сәхнәгә чыгу белән, авыр сугыш елларындагы яшьлек һәм шулкадәр акыллы, тәртипле яшьләр күз алдына килеп баса.

Хәйдәр ролендә Рим Хәйбрахманов. Яшь кенә кеше ничек шушы кадәр оста башкарды ул рольне! Искиткеч матур уйнады! Аңа гашыйк булмаган кыз, сокланмаган кеше калмагандыр. Аның һәрбер кыланышы, һәр кузгалышы, һәр күз карашы, һәр сүзе ихласлык белән башкарылып, тамашачыларның ихтирамын җәлеп итте.

Спектакльдә кечкенә малай ролен башкаручы һәм киләчәктә сәхнә йолдызы булып балкып чыгарга торучы Ильдар Гиззатов бик тә зур осталык күрсәтеп, зур талантка ия булачагын исбат итте.

Минем уемча, газетада А.Андрющенконың мәкаләсе янында шул малайның сәхнәдәге фотосы белән, берничә сүзе дә бирелгән булса, бигрәк тә матур булган булыр иде.

Замананың тыңгысыз һәм борчулы, авыр, мәшәкатьле булуына карамастан, башыаягы белән политикага чумган кеше күңеленә рухи азык бирә, радио, телевизор аша күңел болгаткыч хәбәрләрне тыңлап, гарык булган йөрәкләрне рәхәтләндереп ял иттерүләре өчен бу коллективка тамашачылар исеменнән газета аша рәхмәт белдерәм.

Мөкатдимә Гатауллина. "Камышлы хәбәрләре", Ноябрь, 1992 ел.

Спектакль

24 сентябрьдә Татар Байтуганы авыл клубында үзешчән түгәрәге Г.Камалның "Хафизәләм иркәм" пьесасын сәхнәгә куйды. Тамашачылар спектакльне бик яратып карадылар.

"Югары уңыш өчен". 1953 ел, сентябрь.

Халык театрының 75 нче сезоны

12 апрель көнне Балыклы авылы Мәдәният йортында Камышлы авылы халык театры драматург Кәрим Тинчурин әсәре буенча хәзерләнгән "Сүнгән йолдызлар" исемле спектакльне күрсәтте.

Быел халык театры бу спектакль белән 75 еллык юбилей сезонын ачып җибәрде. "Сүнгән йолдызлар" спектакле халык күңеленә күптән үтеп кергән, йөрәкләрне тетрәндергән әсәр.

Камышлылар бу әсәрнең нечкәлеген спектакльга үзләренә һәрвакытта хас булганча, зур җаваплылык тоеп хәзерләгәннәр. Шуңа да алар һәрбер рольне җиренә җиткереп, матур итеп гәүдәләндереп, тамашачы күңеленә үтеп керделәр.

Сәрвәр, Исмәгыйль, Мәһдүм, Гөлнур әби, Җиһанша, Фәрхи карчык, Фатыйма образларын тудырган Г.Камалетдинова, Р.Шәкуров, Р.Хәйбрахманов, Р.Шәвәлиева, М.Төхбәтшин, Т.Вәлиева, Р.Кадыровалар Балыклы авылы тамашачыларын берничә сәгать буенча иҗат дөньясына алып киткән кебек булдылар. Революциягә кадәр татар халкының тормышын, мәхәббәтен, кичерешләрен тулы итеп, зур тойгы белән башкардылар. "Сүнгән йолдызлар" драма әсәре буларак һәм артистларның оста, "рольгә кереп" уйнавы сәбәпле тамашачыларның күзләрен дә яшьләндерде.

Авылдашларым исеменнән, Камышлы халык театры артистларына зур рәхмәтемне белдерәм, киләчәктә дә сәнгать дөньясында армый-талмый эшләп, уңышларга ирешүләрен телим. Шулай ук гаиләләренә иминлек, исәнлек, тыныч тормыш теләп калабыз. Тагын килегез, хөрмәтле артистлар!

Фәния Ганиева, мәдәният йорты мөдире. "Камышлы хәбәрләре", апрель, 1995 ел.

РОМАН

АРЫШ ТӘМЕ

Мәдинә Маликова.

(Дәвамы)

Айзирәкнең сораулы карашын күреп:

-Скорыйга бер, милициягә ике! Шуннан һәммәсе беленә,-дип, кадак каккандай итеп өстәде аннары.

Айзирәк югалып калган иде. Моңарчы ул, кешедән ишеткәне һәм китаплардан укыганы буенча, исерекләр айныгач хатыннарына яхшыатланалар, дип белә иде.

Гөлүсә апасының: "Айныткычка урамда аунап ятканны алмыйлар, чын эчкечеләрнең акчасы югын беләләр,-дигәне исенә төште. -Алар шул азмаз кыеш-мыеш атлаганны гына аулап йөри дә. Хәзерге вакытта авызына бер дә капмаган ир-ат булса да, мәчет тирәсендә генәдер, бәлки. Әле менә телевизордан күрсәтеләр... Мәскәүдә атка атланган ике милиционер хатын чайкалыбрак барган бер ирне тотып алганнар да, кулына богау салып, ат ияренә бәйләгәннәр. Аларның үз планы бар икән: смена саен биш-алты тәртип бозучыны милиция бүлегенә алып килергә. Теге бичараның ни гомергә бер, иптәшләренең котыртуына бирелеп авызына капкан көне булган. Кайтып җиттем бит инде, өем әнә генә, җибәрегез, дип ялына икән бу. Ә тегеләрнең план үтисе бар! Шуннан машинадан өркепме, башка берәр нәрсәдәнме, атлар дулап чабып киткән дә, теге адәм егылып башын ярган. Хәзер гомерлеккә гарип булып калган ди".

"Айныткычтан алдым җизнәңне",-дигән сүзне ычкындырмады, әмма хәзер аңлашыла: андый хәлләр дә булгандыр, күрәсең. Менә хәзер, бала күтәреп, иренең мыгырдавын тыңлап урам буйлап атлаганда, хәтер түрендә аның сөйләгәннәре, гаепле кешедәй елмаюы җанланды. Ничек тә акларга тырыша иде Гөлүсә ирен. Чөнки ярата иде! Мәхәббәт кешенең гаеп-кыегын шомарта. Айзирәкнең андый шомарткычы юк шул. Шунлыктан аңа Касыйм күңел кайтаргыч, гайрәтне чигергеч булып күренде. Ул, ташып чыгарга торган нәфрәтен басарга тырышып, кулындагы баланы күкрәгенә ныграк кысты-гүяки сабый бу чит-ят, затсыз адәм белән ике арада киртә булып тора, аны саклый иде. Чатка барып җиткәч, Касыйм урамның икенче ягына атлады:

-Син бар кайт! Мин эшкә киттем.

Исенә төшкән!

Өенә кайтып кергәндә, Айзирәк үзен дөм караңгы бушлыкка убылгандай тоя иде. Колак тонган, ми түнгән, тик йөрәкнең сызлавына гына чыдар әмәл юк. Тагын апасының сөйләгәне искә төште. Милиция атының ияренә кулын богаулагач егылып башын ярган ир кебек бит аның хәле дә. Айзирәк тә богауланган, ул да егылды, яраланды...Иң якын кешесе аны, күтәреп торгызасы, кызганасы, юатасы урынга, күңелен яралап, тоз сибә: хатын буларак хурлый, кешелеген таптый. Теге ирнең тәне имгәнгән, Айзирәкнең исә рухы сынып, гарипләнеп калырмы? Ничек яшәп бетерерсең?

Кайчан ялгышты, ни гаебе аркасында мондый җәзага тартылды соң әле ул? Ятим калган сабыйны кызганганы өченме? Ярын ятлар тартып алгач, бәгыре сызланудан хәле бетеп, сөймәгәннең кочагына кергәне өченме? Әйе, ул каралды да агарды кебек. Әмма, икенче яктан караганда, сөймәгәннең кочагына сыенган кыз баланы бер дә мактамыйлар бит. Мондый гамәл гомер-гомергә йә фаҗига, йә бозыклык дип бәяләнгән. Айзирәкне һичкем бозыклыкта гаепли алмый. Ул фаҗигагә юлыкты! Фаҗигагә! Моннан котылу юлы да күренми...

Үзәк өзелә, колак чыңлый, уйлар буталган иде.

-Нишләп болай ишегеңне япмый йөрисең?-дигән тавышка башын күтәреп караса, каршысында Нәзилә карчык басып тора.

-Тагын почтаңны керттем менә,-дип, гәзитләр сузды ул. -Хат та бар икән...Монысына биетеп тормыйм инде... Өстәленә куям менә. Хәерлегә булсын...Сумкам авыр, чыгыйм әле мин...Биклә ишегеңне!

Айзирәк үрелеп хатны алды. Гади конверт, адресы бик матур, әмма ят почерк белән язылган. Камчаткадан. "От Сагитова Заита".

Айзирәк сискәнеп китте. Кабаланып конвертны умырды...

"Исәнме, кызым! Бу хатны сиңа әтиең яза..."

Айзирәкнең күз алдында хәрефләр биешә башлады, бер мәлгә ул күзләрен йомып, зиһенен тупларга тырышты. Бераз аңын җыйгач кына укуын дәвам итте.

"...Бу хатны мин Камчаткадан язам. Ун ел инде шушында яшим. Монда нефтьчеләр зур казыну эшләре башлап җибәрделәр, эшчеләрне төрле җирдән җыйганнар. Безнең Багыштан да өч кеше килеп чыкты. Берсе элекке елларда әниеңдә дәваланган икән, сезнең хәлләрне белә. Гөлүсәнең вафат булганын ишеткәч, миңгерәп киттем, башыма күсәк белән китереп органдай булды. Кызым, күз нурым! Исән генә була күр берүк! Үз тормышыңны коргансың икән, бәхет телим сезгә! Кияүгә миннән күп итеп сәлам әйт! Тату, тыныч яшәгез, безнең хаталарны кабатлый күрмәгез! Язасы сүзләрем кәгазь битләренә сыеп бетәрлек кенә түгел. Баштан күп хәлләр кичте, язмыш төрлечә сынады. Күзләреңә карап, һәммәсен сөйләр идем, аңлатыр идем, каршыңа тезләнеп гафу сорар идем. Монда синең ике энекәшең үсеп килә, Халит ун яшьтә, Хәбиб-сигездә. Алар белән дә таныштырыр идем. Җавап көтәм синнән, балам!"

Айзирәк хатны өстәлгә ташлады да, телефонын алды.

-Исәнме, әни. Әтидән хат килде монда.

Тынлык.

(Дәвамы бар)

Материалларны басмага Рәйсә Төхбәтшина әзерләде.

Котлыйбыз!

Иске Ярмәк авылы
Ралиф Рафаил улы
Шаһиевка-60 яшь

Газиз улым, яраткан абыебыз! Сине ихлас күңелдән юбилеең белән котлыйбыз. Сиңа ныклы исәнлек, бәхетле киләчәк, озын гомер телибез.

Матур таңнар атсын синең өчен,
Тормыш дәртең бер дә сүнмәсен.
Һәр яңа көн сиңа нык исәнлек,
Һәм гомерлек бәхет өстәсен.

Әниең, сеңелләрең Рәмзия, Ризидә, Люция гаиләләре белән.

***

Камышлы авылы
Хәҗәр Шәрәфетдин кызы
Гайнуллинага

Газиз әниебез, сөекле әбиебез! Сине саф күңелдән туган көнең белән котлыйбыз.

Килгән саен синең яннарыңа,
Колач җәеп каршы аласың.
Мең-мең рәхмәт, әни, тәрбияңә,
Безнең өчен һәрчак кирәк син.
Гомерләрең, әни, озын булсын,
Имин булсын дөнья-йортларың.
Беркайчан да сүрелмәсен иде,
Учагында янган утларың.

Балаларың Илдар, Илүсә, Гөлфирә, оныкларың Люция, Равил, Гүзәл, Илмира, Илвина һәм оныкчыкларың.

***

Раил Минегата улы
Хәкимовка-55 яшь

Хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле әтиебез, бабабыз! Сине ихлас күңелдән юбилеең белән тәбриклибез.

Еллар үтә диеп, әти, борчылма син,
Еллар үтү берни түгел ул.
Сау-сәламәт булып озак яшәү,
Үзе бәхет, үзе шатлык ул.
Сиңа рәхмәт сүзен, әтиебез,
Белдерәбез туган көнеңдә.
Үстердең син безне кеше итеп,
Олы рәхмәт барсы өчен дә.

Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың Аделя, Гөлназ, киявләрең Винер, Ригиль, оныгың Расул.

***

Раил Минегата улы Хәкимовка

Газиз улым, яраткан абыебыз! Сине олы йөрәктән юбилеең белән котлыйбыз.

Тыныч лыгың булсын күңелендә,
Эшләрең дә барсын, гөрләсен.
Гомер буе синең йөрәгеңдә,
Яшәү дәрте сүнми дөрләсен.
Бәхет кенә сиңа юлдаш булсын,
Алга таба гомер иткәндә.
Сокланырлык гамәлләрең калсын,
Тормыш йомгакларын сүткәндә.

Әниең, иркәләрең Рамил, Салават, Руфия, Илдар, Алмаз, Гөлназ, Ильяс, Альберт, Руфилә.

***

Раил Минегата улы Хәкимовка

Кадерле, яраткан киявем, җизнәбез, абыебыз! Без сине чын күңелдән юбилеең белән тәбриклибез.

Матур кыш аенда туганга мы,
Күңелендә һәрчак изгелек.
Кылган яхшылыгың кире кайтып,
Күрсәң иде үзең игелек.
Сәламәт һәм озын гомерле бул,
Пар канатың булсын янәшә.
Балаларыңның игелеген күреп,
Гел сөенеп, көлеп син яшә.
Олы җаның, киң күңелең өчен,
Рәхмәт ява сиңа һәркемнән.
Зур бәхетләр, тыныч, якты тормыш,
Изге теләк кабул ит бездән.

Әбиең Әминә, балдызларың Рамилә, Гөлшат һәм аларның гаиләләре.

***

Ремонт стиральных машин. Пенсионерам и инвалидам скидки. Гарантия.
8-927-405-70-40, 8-937-574-54-54, 8-927-042-82-23

Раилә Нәгыйм кызы
Сафинага-50 яшь

Кадерле туганыбыз! Сине чын күңелдән юбилеең белән котлыйбыз. Сиңа ныклы сәламәтлек, озын тыныч гомер телибез. Син изге күңелле, ярдәмчел, юмарт. Тормыш юлың күпләргә үрнәк. Без сине хөрмәт итәбез һәм яратабыз.

Карашларың җылы яңгыр кебек,
Елмаюың айдай сөйкемле.
Шәфкатеңнең иге-чиге юк бит,
Кояш чәчкән нурлар шикелле.
Ак бәхетләр юлдаш булсын сиңа,
Көннәреңне шатлык бизәсен.
Сәламәтлек-үзе бәхет бит ул,
Ходай шуннан мәхрүм итмәсен.

Иң изге теләкләр белән сеңелең Зәмзәмия гаиләсе белән-Иске Ярмәк авылыннан.

***

Иске Усман авылы
Халит Сәлимҗан улы
Вәлиевка-55 яшь

Хөрмәтле тормыш иптәшем, яраткан әтиебез, газиз бабабыз! Сине кайнар йөрәктән юбилеең белән тәбриклибез.

Матур итеп яшисең син җирдә,
Үрнәк бит син безгә һәр эштә.
Озын гомер сиңа теләгәндә,
Амин диеп торсын фәрештә.
Аллаһы сиңа сәламәтлек бирсен,
Бездән сиңа шушы теләкләр.
Синең исән-сау яшәвеңне күреп,
Куансыннар безнең йөрәкләр.

Тормыш иптәшең, балаларың һәм оныкларың Илшат, Ләйсән, Лиана, Тимур, Илвир, Гөлфирә, Радэль, Артур.

***

Балыклы авылы
Гөлнур Әбүзәр кызы
Закировага-55 яшь

Хөрмәтле Гөлнур! Сине ихлас күңелдән юбилеең белән котлыйбыз.

Бүген синең туган көнгә,
Җылы сүзләр килә әйтәсе.
Теләкләрнең иң матурын гына,
Килә сиңа бүген телисе.
Гомер юлларың озын булсын,
Сәламәтлегең дә нык булсын.
Картайганда сине тәрбияләргә,
Барлык балаларың сау булсын.

Изге теләкләр белән сыйныфташың һәм дустың Флюра гаиләсе белән.

***

Яңа Усман авылы
Рамил Таһир улы
Абдрахмановка-50 яшь

Хөрмәтле тормыш иптәшем, әтиебез, кадерле бабабыз, кодам! Сине чын күңелдән юбилеең белән тәбриклибез.

Гаиләдә синдәй ир-ат үрнәк,
Ихтирамлы әти, терәк ир.
Үрнәк әти, терәк ирләр барда,
Чәчәк кебек булыр торган җир.
Без бик шатбыз мондый күркәм кеше,
Безнең өчен якын, кадерле.
Йөз яшькәчә аңа гомер телик,
Бүләк итик кадер-хөрмәтне.

Тормыш иптәшең, кызларың Ләйсән, Юлия, киявең Руслан, оныгың Радмир, кодагыең Фәридә.

***

Рамил Таһир улы Абдрахмановка

Кадерле улым, яраткан энем, абыебыз, туганыбыз! Сине ихлас күңелдән юбилеең белән котлыйбыз.

Без телибез сиңа шатлыкның,
Йөрәккә сыймастай зурысын.
Саулыкның имәндәй ныклысын,
Бәхетнең бары тик тулысын.
Алдагы көннәрең якты булсын,
Нурлы булсын гомер-гомергә.
Безнең белән шау-гөр килеп,
Яшәргә булсын гел бергә.

Әниең, апаң Дания гаиләсе белән һәм туганнарың.

***

Белдерү

Хөрмәтле милләттәшләр!

Быел - театр елы. Безнең дә Камышлыбызда чал тарихы булган Камышлы халык театры эшләп килә. Аңа икенче елга 100 яшь тула. Театрга кагылышы булган һәрбер чагыздан гәҗит аша үзегезнең истәлек-хатирәләрегез белән бүлешүегезне, сакланган фоторәсемнәрегезне дә китерүегезне (алар кире кайтарыла) соралабыз.

Редакция хезмәткәрләре.

Рамил Таһир улы Абдрахмановка

Хөрмәтле киявем, яраткан абыебыз! Сине чын күңелдән туган көнең-юбилеең белән тәбриклибез.

Рухи ныклыкны зур итеп,
Ходай сиңа биргән тумыштан.
Сыгылмыйча, батыр яшисең син,
Тәм-ямь табып тормыштан.
Искиткеч җан синең күкрәгендә,
Янып яши барыбыз өчен дә.
Без телибез сиңа саулык, байлык.
Бәхет, шатлык тормыш күгендә.

Әбиең Зөлфия, иркәләрең Илдар, Илнар гаиләләре белән.

***

Рамил Таһир улы Абдрахмановка

Яраткан җизнәбез, сөекле абыебыз! Без сине кайнар йөрәктән юбилеең белән котлыйбыз.

Сиңа дигән олы хөрмәтебез,
Урын алсын йөрәк түрендә.
Шатлык, бәхет, мул ризыклар,
Бирсен Ходай сиңа гомергә.
Якты көннең һәрбер иртәсе,
Килсен сиңа көлеп, нур булып.
Сәламәтлек, бәхет юллаш булсын,
Куанычлар килсен күренеп.

Бажаң Радик, балдызың Гөлия һәм балалар-Яр Чаллы шәһәреннән.

***

Рамил Таһир улы Абдрахмановка

Газиз энебез, абыебыз! Сине олы йөрәктән истәлекле көнең белән тәбриклибез.

Син яшь әле, чибәр әле,
Чәчләреңә бәсләр кунса да.
Иң кадерле кешебез син безнең,
Ничә генә яшең тулса да.
Шаулап-гөрләп үткән гомереңнен,
Озын булсын алда дәвамы.
Балаларың, оныкларың белән,
Бергәләп үт әле син аны.

Абыең Әхәт, апаң Роза, иркәләрең Лилия, Илдус, Айрат һәм Гыйләҗевлар гаиләсе.

***

Рамил Таһир улы Абдрахмановка

Хөрмәтле кешебез! Сине ихлас күңелдән туган көнең белән котлыйбыз.

Котлы булсын юбилеең,
Телибез бәхет кенә.
Сөендерсен һәрбер көнең,
Шатлыклар килеп кенә.

Бажаң Ирек, апаң Әфидә һәм балалар гаиләләре белән.

***

Илдар Миннулла улы
Шатдиновка-50 яшь

Кадерле улым, энем! Сине ихлас күңелдән юбилеең белән тәбриклибез.

Юбилеең котлы булсын,
Гомер юлың озын булсын.
Балаларың, туганнарың белән,
Өй түрләрең тулып торсын.

Әниең, абыең Ринат.

***

Илдар Миннулла улы Шатдиновка

Сөекле энебез, яраткан абыебыз! Сине чын күңелдән юбилеең белән котлыйбыз.

Күпләр микән синең кебек,
Изге җанлы, туган бәгырьле.
Без бит сине бик тә яратабыз,
Син бит безгә бик тә кадерле.

Абыең Ирек, җиңгәң Әфидә һәм аларның балалары Юлия, Лилия, Рания гаиләләре белән.

***

Чулпан поселогы
Руслан Тәлгать улы
Бикмөхәммәтовка-45 яшь

Газиз улыбыз! Сине кайнар йөрәктән юбилеең белән тәбриклибез.

Фәрештәләр һәрчак юлдаш булсын,
Бәхет булсын һәрчак юлында.
Үтәр юлың сикәлтәсез булсын,
Изге дога йөртсен юлында.

Әтиең, әниең.

***

Руслан Тәлгать улы
Бикмөхәммәтовка

Яраткан тормыш иптәшем, сөекле әтиебез, бабабыз! Сине олы йөрәктән истәлекле бәйрәмең белән котлыйбыз.

Якты өмет, олы шатлыклар,
Һәрчак сиңа юлдаш булсыннар.
Уңышлардан килгән куанычлар,
Күңел күгең бизәп торсыннар.

Тормыш иптәшең, улың Сабир, кызларың Юлия, Алина гаиләләре белән.

Поздравляем!

Коллектив ООО «Родник» горячо поздравляет сотрудника Р.М.Хакимова с 55-летием.

Уважаемый Раиль Минугатаевич!

У Вас сегодня милый праздник
И рады мы поздравить от души.
И пожелать Вам много-много счастья,
Успехов и душевной теплоты.

***

Село Камышла
Хакимову Раилю
Минугатаевичу-55 лет

Дорогой брат, любимый дядя! От всей души поздравляем тебя с юбилеем.

В этот день вспоминать приятно
Счастливые и радостные дни.
Еще приятней-снова строить планы,
Пусть непременно сбудутся они.
Пускай здоровье поможет,
Все замыслы легко осуществить.
И рядом будут близкие, родные,
Чтоб с ними эту радость разделить.

Брат Рафис, сноха Галина, племянники Сергей, Аня, Юля, Марат, Алина.

***

Петровой Анастасии Игоревне-15 лет

Милая внученька, сестренка! От всего сердца поздравляем тебя с днем рождения.

Цветы, открытки, поздравленья,
Пятнадцать лет, вот это да!
Денек отличный, день рожденья,
И ты красотка, ты звезда.
Легко желаем, с наслажденьем,
Учиться счастье познавать.
Идти по жизни с настроеньем,
И много радостей познать.

Дедушка, бабушка, сестра Алина.

***

Петровой Анастасии Игоревне

Любимая наша племянница, тетя! Сердечно поздравляем тебя с днем рождения.

Мы с днем рождения поздравляем
И от души тебе желаем.
В твоих пятнадцать полных лет,
Цветов, улыбок и конфет.
Пускай везет всегда, повсюду,
Пусть все получится на пять.
Друзья, родные рядом будут
Хвалить тебя, любить и ждать.

Тетя Татьяна, дядя Юрий, братишки Богдан, Михаил.

ПОДАРИТЕ СТАРОЙ ОБУВИ НОВУЮ ЖИЗНЬ!
12 ФЕВРАЛЯ в с.Камышла в РДК им. А.Давыдова с 14.00 до 17.00 часов Кировская обувная фабрика принимает обувь на ремонт (замена подошвы, союзки, задника, изменение фасона, размера обуви, меняем острые, квадратные носы на круглые, с высокого каблука ставим на низкий, замена каблуков, обрезание носов, ремонт любой сложности). Качество фабричное, материалы натуральные.
Тел: 8-963-433-09-04.

Руслан Тәлгать улы
Бикмөхәммәтовка

Кадерле энебез, абыебыз! Сине саф күңелдән юбилеең белән тәбриклибез.

Кышкы айда туганга дыр,
Ак-саф булды синең күңелең.
Шатлык-куанычлар белән үтсен,
Ходай язган калган гомерең.

Апаң Зөлфия, җизнәң Рамил һәм балалар.

***

Алия Әхмәтгазый кызы
Мөхәммәтҗановага

Сөйкемле кодагыебыз! Сине ихлас күңелдән туган көнең белән котлыйбыз.

Бүләгебез саф теләкләр,
Бездән сиңа, кабул ит.
Изгелектә, рәхәтлектә,
Иминлектә гомер ит.
Бәхетнең ак нурлары,
Балкысын йөзеңдә.
Исән-таза, матур булып,
Яшә әле син җирдә.

Кода-кодагыең-Иске Ярмәк авылыннан.

Адрес редакции и издателя:
446970 Самарская область
Камышлинский район
с. Камышла
ул. Победы, 37 А
e-mail: miznur@mail.ru
www.kamizvestiya.ru
12+

Телефоны:
Руководитель: 3-31-47,
ответственный секретарь, корреспонденты, верстка, рекламный отдел: 3-30-61.
За содержание рекламы ответственность несет рекламодатель

Руководитель центра и главный редактор Р.Т.БАДРЕТДИНОВ.
Газета выходит по вторникам и пятницам.
Объем - 1 печатный лист.
Отпечатана в МУП "Сергиевское полиграфическое предприятие". 446540 Самарская область, с.Сергиевск, ул.Ленина, 14. Заказ №151

Номер подписан в печать 7.02.2019 г. фактически в 12.00 по графику в 12.00

Ответственный секретарь: И.ГАЙНУЛЛИНА
Верстка: Р.ПОЛУКАРОВ.
Подписной индекс 52436
Цена свободная. Тираж - 1300 экз.

Редакция может не разделять точку зрения автора. Присланные материалы могут подвергаться редакционной правке. Редакция не несет ответственности за содержание рекламных материалов, их политическую направленность и правдивость. Письма, рукописи, иллюстрации не рецензируются и не возвращаются.

Учредители: Администрация муниципального района Камышлинский Самарской области. Газета "Камышлинские известия" зарегистрирована в Управлении Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Регистрационный номер ПИ № ТУ 63-00744 от 02 декабря 2014 года.